**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2719**
**27.05.2022**

«Акварель-2022» шәһәр чәчәкләр
фестивален үткәрү турында

Шәһәр халкының һәм оешмаларының иҗади потенциалын ачыклау һәм аларны шәһәр территорияләрен чәчәкле-декоратив бизәүгә җәлеп итү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә «Акварель-2022» шәһәр чәчәкләр фестивален (алга таба – чәчәкләр фестивале) 2022 елның 1 июненнән 30 августына кадәр үткәрергә.

2. Расларга:

1) шәһәр чәчәкләр фестивале конкурслары турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) шәһәр чәчәкләр фестиваленә әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә шәһәр чәчәкләр фестиваленә әзерлек һәм аны үткәрү чаралары планын төзергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 27 маендагы
2719 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Акварель-2022» шәһәр чәчәкләр фестивале
конкурслары турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Акварель-2022» шәһәр чәчәкләр фестивале конкурслары (алга таба – конкурслар) шәһәр халкының, оешмаларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең чәчәкләр белән бизәү һәм яшелләндерү өлкәсендә иҗади потенциалын ачыклау һәм бүләкләү, вертикаль яшелләндерүне, түбәләрдәге бакчаларны, яшел стеналарны стимуллаштыру һәм үстерү, балконнар һәм тәрәзәләрне, күпфатирлы йортларга керү төркемнәрен чәчәкләр белән бизәүне яхшырту максатында үткәрелә.

2. «Акварель-2022» шәһәр чәчәкләр фестивале (алга таба – чәчәкләр фестивале) кысаларында түбәндәге конкурслар үткәрелә:

1) Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерү, яшелләндерү һәм чәчәкләр белән бизәү буенча конкурс – 2022 елның 1 августыннан 17 августына кадәр;
2) «Чәчәкләрдән күләмле композиция» – 2022 елның 30 августы;
3) «Чәчәкләрдән картина» – 2022 елның 30 августы;
4) «Чәчәк колоннасы яки аркасы» – 2022 елның 30 августы;
5) «Яшел стена» – 2022 елның 30 августы;
6) «Вертикаль яшелчә бакчасы» – 2022 елның 30 августы;
7) «Маскарад костюмы» – 2022 елның 30 августы;
8) «Чәчәкләр патшабикәсе» – 2022 елның 30 августы.

Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерү, яшелләндерү һәм чәчәкләр белән бизәү буенча конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) «Иң яхшы күпфатирлы торак йорт ишегалды»;
2) «Керү төркемен чәчәкләр белән иң яхшы бизәү»;
3) «Шау чәчәкле йорт»;
4) «Иң яхшы чәчәклек».

3. Конкурсларда катнашу өчен оешмалардан, шәхси эшмәкәрләрдән, шәһәр халкыннан әлеге нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча шәхси һәм коллектив заявкалар кабул ителә һәм карала.

4. Чәчәкләр фестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитетының (алга таба – оештыру комитеты) составы Башкарма комитет карары белән раслана.

5. «Чәчәкләрдән күләмле композиция» конкурсында катнашуга заявкалар 2022 елның 1 июненнән 2 августына кадәр срокта оештыру комитеты тарафыннан түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 423 кабинет, тел. 30-59-52, 30-58-01, e-mail: ispolkom85@mail.ru.

6. «Яшел стена» конкурсында катнашуга заявкалар 2022 елның 3 августыннан 20 августына кадәр срокта оештыру комитеты тарафыннан түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 423 кабинет, тел. 30-59-52, 30-58-01, e-mail: ispolkom85@mail.ru.

7. Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерү, яшелләндерү һәм чәчәкләр белән бизәү буенча конкурста катнашуга заявкалар 2022 елның 13 июленнән 30 июленә кадәр түбәндәге телефон-факслар буенча кабул ителә:

1) Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте: 54-76-76, 32-98-36;
2) Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте: 47-55-49, 47-55-39;
3) Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте: 71-42-24, 70-17-59.

8. Түбәндәге конкурсларга заявкалар 2022 елның 3 августыннан 20 августына кадәр Башкарма комитет район хакимиятләренең әлеге нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән телефон-факслары буенча кабул ителә:
1) «Чәчәкләрдән картина»;
2) «Чәчәк колоннасы яки аркасы»;
3) «Вертикаль яшелчә бакчасы»;
4) «Маскарад костюмы»
5) «Чәчәкләр патшабикәсе».

9. Әлеге нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән конкурсларда катнашуга заявкада түбәндәгеләр күрсәтелә:
1) физик затлар өчен:
- конкурсның исеме;
- катнашучының исеме, эш яки уку урыны;
- катнашучының салым түләүченең паспорт мәгълүматлары һәм идентификация номеры (алга таба – ИНН) (балигъ булмаганнар өчен әтисе яки әнисенең паспорт мәгълүматлары һәм ИНН);
- катнашучының элемтә телефоны;
2) юридик затлар өчен:
- конкурсның исеме, катнашучының категориясе (муниципаль учреждениеләр, коммерция оешмалары);
- оешманың рәсми исеме, урнашу урыны;
- җитәкченең һәм җаваплы затның исеме, җаваплы затның элемтә телефоны.

## 2 бүлек. Конкурсларны оештыру һәм үткәрү

10. Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:
1) конкурсларның жюри (алга таба – жюри) составын формалаштыра;
2) оештыра:
- жюри эшен;
- дипломнар әзерләүне;
- конкурста җиңүчеләргә дипломнар тапшыруны;
3) массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту өчен конкурслар уздыру һәм аларның нәтиҗәләре турында материаллар тапшыра;
4) конкурста катнашучыларга экспозицияләрне урнаштыру схемасын һәм үлчәмнәрен бирә;
5) жюри утырышларын үткәрү өчен бүлмә бирә;
6) конкурста катнашучылар тарафыннан тапшырылган материалларны кабул итүне һәм аларның сакланышын тәэмин итә.

11. Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерү, яшелләндерү һәм чәчәкләр белән бизәү буенча конкурс (алга таба – төзекләндерү буенча конкурс) ике этапта үткәрелә:
1) район – шәһәрнең тиешле районнар территориясендә җиңүчеләрне билгеләү;
2) шәһәр – шәһәрнең тиешле районнар территориясендәге призерлар арасыннан җиңүчеләрне билгеләү.

12. Төзекләндерү буенча конкурсның район этабы 2022 елның 1 августыннан 8 августына кадәр үткәрелә.

13. Төзекләндерү буенча конкурсның район этабын оештыру һәм үткәрү өчен Башкарма комитетның район хакимиятләре Башлыклары тарафыннан конкурсның

район этабын үткәрү буенча конкурс комиссияләре (алга таба – район конкурс комиссияләре) төзелә.

14. Район конкурс комиссияләре түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) төзекләндерү буенча конкурсның потенциаль катнашучыларына конкурсның район этабын үткәрү турында хәбәр итә;

2) Башкарма комитетның Автозавод, Үзәк, Комсомол районнары хакимиятләренең телефон-факслары буенча әлеге нигезләмәнең 7, 8 пунктларында күрсәтелгән конкурсларда катнашуга заявкалар кабул итә;

3) әлеге нигезләмәнең 3 бүлегендә күрсәтелгән объектларны бәяләү критерийлары нигезендә, төзекләндерү буенча конкурста катнашуга тәкъдим ителгән объектларга бәя бирә;

4) оештыру комитетына бирә:

- 2022 елның 9 августыннан соңга калмый төзекләндерү буенча конкурсның район этабын үткәрү барышы һәм аның нәтиҗәләре турында беркетмә рәвешендә мәгълүмат;

- 2022 елның 20 августыннан соңга калмый «Чәчәкләрдән картина», «Чәчәк колоннасы яки аркасы», «Вертикаль яшелчә бакчасы», «Маскарад костюмы», «Чәчәкләр патшабикәсе» конкурсларында катнашучыларның заявкаларын һәм исемлеген, катнашучылар турында заявкалардагы мәгълүматларны күрсәтеп.

15. Район конкурс комиссияләре тарафыннан төзекләндерү буенча конкурсның район этабына тиешле номинацияләрдә йомгак ясала һәм ул район конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм оештыру комитетына тапшырыла.

16. Төзекләндерү буенча конкурсның шәһәр этабы 2022 елның 10 августыннан 18 августына кадәр үткәрелә. Төзекләндерү буенча конкурска тәкъдим ителгән объектларны бәяләү урынга барып, әлеге нигезләмәнең 3 бүлегендә билгеләнгән объектларны бәяләү критерийларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## 3 бүлек. Конкурсны бәяләү критерийлары

17. Төзекләндерү буенча «Иң яхшы күпфатирлы торак йорт ишегалды» номинациясендә катнашучылар – торак идарә компанияләре, торак милекчеләре ширкәте.

Күпфатирлы торак йортлар ишегалларының төзекләндерелгән территорияләре санын арттыру максатында, «Иң яхшы күпфатирлы торак йорт ишегалды» номинациясенә әлегә кадәр төзекләндерү буенча конкурста катнашмаган яки кимендә өч ел элек катнашкан ишегалды территорияләре тәкъдим ителә.

Төзекләндерү буенча күрсәтелгән номинациядә конкурска чыгарыла торган объектлар түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) архитектура-ландшафт чараларын файдаланып, ишегалдының индивидуаль мохитен формалаштыру:

- торак йортларның керү төркемнәре, ял почмаклары, беседкалар булу, аларның торышы (тышкы күренеше) һәм бизәлеше;

- балалар, спорт мәйданчыклары булу, аларның торышы һәм бизәлеше;

- балалар мәйданчыкларында түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган мәгълүмат такталары булу:

- җиһаздан файдалану кагыйдәләре һәм яшь буенча таләпләр;

- коткару хезмәте, ашыгыч ярдәмнең телефон номерлары;

- җиһазның төзексезлекләре һәм ватылуы турында хәбәр итү өчен эксплуатация хезмәтенең телефон номерлары;

- ГОСТ Р52301-2013 нигезендә, балалар мәйданчыгында урнашкан уен җиһазын тикшерү журналлары һәм уен җиһазының техник торышын күзәтү һәм контрольдә тоту, шулай ук тикшерү барышында ачыкланган уен җиһазыннан файдалану кагыйдәләрен бозу очракларын һәм уен җиһазының төзексезлекләрен бетерү турында билгеләр булу;

- торак йортларның керү төркемнәрен бизәгәндә чәчәк контейнерлары, асылмалы вазоннар, вертикаль яшелләндерү һәм чәчәклекләр булу;

- подъездлар янында эскәмияләр һәм чүп урналары булу, аларның торышы;

2) уңайлы эстетик һәм экологик шартлар формалаштыру өчен яшел утыртмалардан файдалану:

- чәчәкләр белән бизәүнең оригинальлеге (гадәти булмавы) һәм сыйфаты (альп тауочыгы, күләмле фигура, күп яруслы вазоннар, вертикаль яшелләндерү һәм башка шундый элементлар булу);

- агач һәм куакларның торышы һәм аларны карау: корыган ботаклар булмау, төрле формага кертеп кисү;

- газоннарның торышы (бозылган участоклар булмау, үләннәрнең биеклеге 15 сантиметрдан артык түгел);

3) ишегалдының санитар торышы;

4) җирле юллар, керү юллары, тротуарлар һәм җәяүлеләр йөри торган юлларның, кунаклар өчен автомобиль кую урыннарының техник һәм санитар торышы.

18. Төзекләндерү буенча конкурсның «Керү төркемен чәчәкләр белән иң яхшы бизәү» номинациясендә карау өчен, катнашучы милек хокукында яки башка законлы нигездә ия булган бинаның, корылманың керү төркемен чәчәкләр белән бизәү буенча конкурс материаллары кабул ителә. Шәһәр территориясен чәчәкләр белән бизәүне стимуллаштыру максатында төзекләндерү буенча конкурсның «Керү төркемен чәчәкләр белән иң яхшы бизәү» номинациясенә мондый конкурста кимендә ике ел катнашмаган керү төркемнәре тәкъдим ителә.

Номинациядә катнашучылар өч категориягә бүленә:

1) муниципаль учреждениеләр;

2) коммерция оешмалары;

3) башка оешмалар.

19. Төзекләндерү буенча конкурсның «Керү төркемен чәчәкләр белән иң яхшы бизәү» номинациясенә тәкъдим ителә торган объектлар түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) чәчәкле-декоратив үсемлекләр белән асылмалы вазоннар булу (күрсәтелгән объектларның эстетик торышы, кашполарны урнаштыруның архитектура – планлаштыру һәм декоратив өстенлекләре);

2) керү төркеме янында җиргә утыртылган үсемлекләрдән вертикаль яшелләндерү булу;

3) бинаның, төзелмәнең, корылманың фасады (фасадны бизәү сыйфаты, архитектура үзенчәлекләре, тышкы күренеше, тәрәзәләрне яки балконнарны чәчәкләр белән бизәү);

4) йорт яны участокларында чәчәклекләр булу һәм аларны карап тотуның сыйфаты, чәчәклекләрнең, газоннарның матурлыгы.

20. Шәһәр территориясен чәчәкләр белән бизәүне үстерүне стимуллаштыру максатында, төзекләндерү буенча «Иң яхшы чәчәклек» номинациясенә элек әлеге конкурста катнашмаган яки төзекләндерү буенча конкурста кимендә ике ел элек катнашкан чәчәклекләр тәкъдим ителә. Чәчәклекләрнең мәйданы 100 кв.м ким булмаска тиеш. Номинациядә катнашучылар ике категориягә бүленә:

1) эшчәнлегенең устав максаты булып шәһәр территориясен яшелләндерү һәм төзекләндерү торган оешмалар;

2) башка оешмалар.

21. Төзекләндерү буенча «Иң яхшы чәчәклек» номинациясендә конкурска тәкъдим ителә торган объектлар түбәндәге критерийлар нигезендә бәяләнә:

1) чәчәклекне төзү һәм аны карау технологияләрен үтәү;

2) чәчәклекләрдә күпьеллык чәчәкле-декоратив үсемлекләрнең һәм куаклыкларның өлеше (чәчәкле-декоратив композициянең гомуми мәйданының 40% ким түгел);

3) чәчәклекләрдә инерт материаллардан файдалану;

4) әйләнә-тирә ландшафт белән ярашу;

5) чәчәклекнең оригинальлеге, гадәти булмавы;

6) чәчәк үсемлекләрен төре, төсе, биеклеге һәм чәчәк ату дәвамлылыгы буенча сайлау.

22. «Шау чәчәкле йорт» номинациясендә катнашучылар ике категориягә бүленә:

1) муниципаль учреждениеләр;

2) коммерция оешмалары.

Шәһәр территориясен чәчәкләр белән бизәүне үстерүне стимуллаштыру максатында, төзекләндерү буенча «Шау чәчәкле йорт» номинациясенә элек әлеге конкурста катнашмаган яки төзекләндерү буенча конкурста кимендә ике ел элек катнашкан чәчәклекләр тәкъдим ителә.

23. Төзекләндерү буенча «Шау чәчәкле йорт» номинациясендә конкурска тәкъдим ителә торган объектлар түбәндәге критерийлар нигезендә бәяләнә:

1) балконнар һәм тәрәзәләрнең гомуми санында чәчәкле-декоратив үсемлекләр белән бизәлгәннәренең өлеше;

2) күпфатирлы йорттагы керү төркемнәренең гомуми санында чәчәкле-декоратив үсемлекләр белән бизәлгәннәренең өлеше;

3) чәчәкле-декоратив үсемлекләрнең һәм кашполарның эстетик торышы.

24. «Чәчәкләрдән күләмле композиция» конкурсының темасы булып «Чәчәк ат, Чаллым!» тора.

25. «Чәчәкләрдән күләмле композиция» конкурсында катнашучылар түбәндәге категорияләргә бүленә:

1) муниципаль учреждениеләр һәм башка коммерцияле булмаган оешмалар;

2) коммерция оешмалары.

26. «Чәчәкләрдән күләмле композиция» фестиваль конкурсының экспозициясен ясау 2022 елның 28 августыннан 2022 елның 29 августына кадәр гамәлгә ашырыла.

27. Утырта торган, инерт, үсемлек материаллар, җир, ком белән катнашучы үзен-үзе тәэмин итә. Оештыру комитеты конкурсантка экспозицияләрне урнаштыру схемасын бирә.

28. Конкурсант бирелгән мәйданнан булган номинация нигезендә һәм утыртмаларны исәпкә алып файдалана ала. Композиция әйләнә-тирә ландшафтка гармоник ярашырга тиеш.

29. Композицияләр территориясендә түбәндәгеләрне күздә тотарга:

1) конкурска 2022 елның 30 августындагы күргәзмә барышында үзләренең куллану үзлекләрен һәм эстетик күренешен саклый торган, кашпода үсеп утыручы чәчәкле-декоратив һәм агач-куак үсемлекләрдән, үсемлек һәм инерт материаллардан, шул исәптән үсемлек материаллардан торган скульптуралар һәм башка кече архитектура формаларын файдаланып эшләнгән, мәйданы 100 кв. м ким булмаган композицияләр тәкъдим ителә;

2) чәчәк капламының мәйданы композициянең гомуми мәйданының кимендә 70% тәшкил итәргә тиеш;

3) композицияләр территориясен киртәләү табигый материаллардан (агач) булырга тиеш;

4) композицияләр нигезенең өслеге табигый материаллардан (рулонлы газон, табигый газон) булырга тиеш;

5) композицияләр территориясендә кичке яктырту, иллюминация.

30. Күргәзмә ачылыр алдыннан конкурсант үзенең экспозициясе янында мәгълүмат табличкасы урнаштыра. Табличкада күрсәтелә: фестивальнең исеме, башкаручы ошманың исеме.

31. Күләмле композицияләрне бәяләү жюри тарафыннан 2022 елның 30 августында үткәрелә.

32. «Чәчәкләрдән күләмле композиция» конкурсына тәкъдим ителгән объектлар түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) фестивальнең тематикасына туры килү;

2) сәнгатьчә күркәмлек;

3) файдаланылган, шул исәптән ампель (чормалып үсә торган, үрмәле) үсемлекләрнең саны;

4) композиция һәм идеянең оригинальлеге (гадәти булмавы);

5) композицияне башкару техникасы һәм сыйфаты.

33. «Чәчәкләрдән картина» конкурсында катнашучылар түбәндәге категорияләргә бүленә:

1) эшчәнлегенең устав максаты булып шәһәр территориясен яшелләндерү һәм төзекләндерү торган оешмалар;

2) муниципаль учреждениеләр;

3) башка оешмалар, гражданнар берләшмәләре.

34. «Чәчәкләрдән картина» конкурсына үсемлек материалдан эшләнгән 2х2м үлчәмдәге картиналар кабул ителә, чәчәк капламының мәйданы картинаның гомуми мәйданының кимендә 80 процентын тәшкил итәргә тиеш. Картиналарның 20х10 см үлчәмдәге этикеткасы булырга тиеш, ул астагы уң почмакка беркетелә. Этикеткада картинаның исеме, ошманың исеме, авторның исеме күрсәтелә.

35. «Чәчәкләрдән картина» конкурсына тәкъдим ителгән объектлар түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) катнашучы тәкъдим иткән темага туры килү;

2) сәнгатьчә күркәмлек;

3) композиция һәм идеянең оригинальлеге (гадәти булмавы);

4) композицияне башкару техникасы һәм сыйфаты.

36. «Чәчәк колоннасы яки аркасы» конкурсында катнашучылар ике категориягә бүленә:

1) һәвәскәр бакчачылар;

2) муниципаль учреждениеләр һәм башка коммерцияле булмаган оешмалар.

37. «Чәчәк колоннасы яки аркасы» конкурсына биеклеге 1,5 м ким булмаган чәчәкле-декоратив үсемлекләр белән бизәлгән колонна яки арка формасындагы вертикаль кашполар кабул ителә.

38. «Чәчәк колоннасы яки аркасы» конкурсына тәкъдим ителгән объектлар түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) үсемлекләрнең, кашпоның эстетик торышы;

2) композициянең сәнгатьчә күркәмлеге;

3) композицияне башкару техникасы һәм сыйфаты.

Объектларның (композицияләрнең) 20х10 см үлчәмдәге этикеткалары булырга тиеш, ул астагы уң почмакка беркетелә. Этикеткада картинаның исеме, оешманың исеме, авторның исеме күрсәтелә.

39. «Вертикаль яшелчә бакчасы» конкурсы һәвәскәр бакчачылар арасында үткәрелә.

Конкурска бакча, яшелчәчелек, дача участокларында үстерелгән, биеклеге 1,5 м, киңлеге 1 м ким булмаган вертикаль кашполар кабул ителә. Экспонатларның 20х10 см үлчәмдәге этикеткалары булырга тиеш, ул объектның уң ягына урнаштырыла яки

беркетелә. Этикеткада экспозициянең исеме, конкурста катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, элемтә өчен телефон күрсәтелә.

40. «Яшел стена» конкурсы шәһәр чәчәкләр фестивалендә катнашучы сәүдә оешмалары, шәхси эшмәкәрләр арасында үткәрелә.

Конкурска вертикаль яшелләндерү объектлары кабул ителә: биеклеге 2 м ким булмаган һәм киңлеге 1,5 м ким булмаган тере үсемлекләр белән чәчәкле-декоратив бизәлгән күп ярусны вертикаль кашполар, алар 2022 елның 30 августында фестивальдә сәүдә объекты белән янәшә урнаштырыла.

41. Объектлар түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) объектта урнаштырылган чәчәкле-декоратив үсемлекләрнең эстетик торышы;

2) объектның сәнгатьчә күркәмлеге;

3) «стенаны» башкару техникасы һәм сыйфаты.

42. «Маскарад костюмы» конкурсында 7 яшьтән 14 яшькә кадәрге балалар катнаша.

43. «Чәчәкләр патшабикәсе» конкурсында 15 яшьтән 17 яшькә кадәрге кызлар катнаша.

44. «Чәчәкләр патшабикәсе» һәм «Маскарад костюмы» конкурсларын бәяләү критерийлары:

1) тәкъдим ителгән темага туры килү;

2) матурлык;

3) костюмның оригинальлеге (үзенчәлекле булуы, гадәти булмавы);

4) костюмны эшләү сыйфаты;

5) костюмның визит карточкасы (дәвамлылыгы 3 минуттан артмаган бию, җыр яки шигырь).

## 4 бүлек. Конкурсларның йомгаклары

45. Конкурс эшләрен бәяләү жюри тарафыннан биш баллы система буенча әлеге нигезләмәнең 3 бүлегендә билгеләнгән конкурс критерийлары нигезендә башкарыла. Бәяләү нәтиҗәләре буенча, жюри һәр конкурс, номинация һәм катнашучы категориясе буенча беренче, икенче һәм өченче урын бирү турында карар кабул итә.

46. Карар конкурсның һәр катнашучысына карата ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш нигезендә кабул ителә һәм утырышта катнашучы жюри әгъзалары тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

47. Конкурсларның һәр номинациясендә һәм категориясендә җиңүчеләр дипломнар белән бүләкләнәләр.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

«Акварель-2022»
шәһәр чәчәкләр фестивале
конкурслары турында
нигезләмәгә кушымта

Форма

«Акварель-2022» шәһәр чәчәкләр фестивале конкурсларында катнашуга

заявка

Шәһәр чәчәкләр фестивале – 2022
оештыру комитеты
рәисе урынбасары,
Башкарма комитет Җитәкчесенең
беренче урынбасары
И.С. Зуевка

Мин, ____________________________________________________________________
катнашучының (физик затлар өчен), оешма җитәкчесенең Ф.И.А.и.

________________________________________________________________________

(оешманың тулы исеме)

________________________________________________________________________

(физик затлар өчен - вазыйфасы, уку яки эш урыны, укучылар өчен – сыйныф номеры)

Сездән 2022 елгы чәчәкләр фестиваленең ___________________________ конкурсында

(конкурсның исеме)

__________________________________________________________ номинациясенең
___________________________________________________ категориясендә катнашуга

композициянең, костюмның исеме

заявка алуыгызны сорыйм.

Оешманың (физик затлар өчен яшәү урынының) почта адресы

________________________________________________________________________

Паспорт мәгълүматлары (физик затлар өчен – 14 яшьтән, 14 яшькә кадәр – әтисе яки әнисенең мәгълүматлары)

________________________________________________________________________

(бирү датасы, кем тарафыннан бирелгән, прописка урыны)

Барлык катнашучылар өчен элемтә телефоны ________________________________

Дата Гариза бирүченең имзасы

Башкарма комитетның
2022 елның 27 маендагы
2719 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Акварель-2022»
шәһәр чәчәкләр фестивален әзерләү һәм
үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| № т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Салахов Ф.Ш. | оештыру комитеты рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2. | Зуев И.С. | оештыру комитеты рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| комитет әгъзалары: | | |
| 3. | Гайнуллин И.Н. | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 4. | Ганиев А.С. | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 5. | Кропотова Н.А. | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 6. | Мулюкова С.Р. | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы |
| 7. | Тарабукин А.С. | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| 8. | Хәбибуллин Ф.Ф. | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| 9. | Хәлимов Р.М. | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 10. | Харисов В.Х. | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева